Рузаевка районы Татар Пешләсе авылында 1407 хужалык, аларда барлыгы 3703 кеше яши. Авыл кvп милләтле: татарлар, руслар, мукшылар, тажиклар, әрмәннәр һәм башкалар дус тора. Бvгенге кондә авылда 17 бала туган һәм 16- бакыйлыкка кvчкән. Пешлә яшьләре «Ипотека» программасы буенча йортлар тозиләр.
Авыл администрациясен икенче ел Ринат Дявлюк улы Шабаев житәкли. Ул авылынын тозеклеген, тынычлыгын, мәнфәгатьләрен яклау очен кочен кызганмый. Шул елда Татар Пешләсе авылында 75 урынга балалар бакчасы ачылган, гомуми урта мәктәбенә 23 укучы белем алырга дип килгән. Үткән уку елына караганда 5 балага артык. Авыл Мәдәният Йорты бинасынын тvбәсенә капиталь ремонт бирелгән. Луговая урамы, Школьная переулогы асфальт юлы ремонтланган, Советская белән Заречнаяга - чокырлы ремонт ясалган. Әмма алда Пешләнен 32 километрга сузылган 35 урамы юлларын ремонтлыйсы бар әле. Луговой һәм Овражная урамнары юлларын ремонтлый башлаганнар (шебень сибелгән), Республика бюджетыннан финанслар килгәч, Колхозная урамы юлын ремонтларга тотынырлар.
Авылда ике мәчет эшләп килә. Икесендә дә 5 июль конне зурлап Ураза аетын укып бәйрәм иткәннәр. Кунаклар да кvп булган. Район житәкчесе Нина Васильевна Иняткина да моселманнарны Ураза бәйрәмебез белән котлап изге теләкләрен юллаган. Ринат Дявлюк улы әйткәнчә, авыл администрациясе белән мәчетләр тыгыз элемтәдә; ярдәмләшеп зур эшләрне башкаралар. Менә Ает бәйрәмен тиешенчә оештырып vткәргәннәр: бәйрәмебезне зурлаганнар.
Алда зур планнар булган чакта, акча – хәлиткеч фактор. Ул һәрвакыт житми, Авыл администрациясенен бюджеты турында әйтәсе дә юк. Пешлә халкынын тырышлыгы һәм иганәчеләрнен матди ярдәме белән кvп эшләр тормышка аша бу авылда. Татар Пешлә авылы Советы депутат эшмәкәрләргә, акчалата аеруча зур ярдәм кvрсәткән Овчинников Ильдар Сирач улына (кибетләр челтәре), Резепов Шәvкәт Мустәкыйм улына («Металлист» предприятиясе), фермер Дубинников Раис Бартан улына, Чалдаев Ильшат Идрис улына (машиналар ремонлау) һәм бердән-бер хатын-кыз, 40 елд

[redacted]